ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2022 г. Казань № 189-33/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карары белән «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга 2022 елга билгеләнгән озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №649-173/кс-2021 карарын көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Югары Судының 2022 елның 1 апрелендәге 3а-273/2022 номерлы карарын, Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының №66а-1767/2022 эш буенча 2022 елның 23 августындагы билгеләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 3 октябрендәге 29-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №649-173/кс-2021 карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карары белән билгеләнгән 2022 елга озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү турында» 16.12.2021 №649-173/кс-2021 карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 августына кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 534-213/кс-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.10.2022 № 189-33/тп-2022
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы
«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен салкын суны транспортлаганга һәм агынты суларны транспортлаганга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Салкын суны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ | | | |
| 1.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 16,37 | 16,35 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 22,89 | 22,94 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 13,84 | 13,83 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.08.2022 кадәр | 13,84 | 13,83 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге